ГЛАВА СТАРОКАШИРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ КӘШЕР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

2022 ел 20 апрель

№ 1

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Кәшер авыл җирлеге территориясендә җирләрдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында карар проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында

«Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 30 апрелендәге 123-ФЗ номерлы Федераль законы, «Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» Федераль законның 1 статьясы һәм «Җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү тәртибе турында нигезләмәне гамәлгә кертү тәртибе хакында» Россия Федерациясе Югары Советы карарының һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» Федераль законның 1 статьясы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 30 декабрендәге 476-ФЗ номерлы Федераль законның 5 статьясы, «Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында» 2021 елның 19 апрелендәге 33 номерлы Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Советы карары, «Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен кабул итү турында» 2021 елның 6 маендагы 4 номерлы Сарман муниципаль районының Иске Кәшер авыл җирлеге Советы карары, Иске Кәшер авыл җирлеге Советының 2021 елның 15 декабрендәге 18 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Кәшер авыл җирлегендә ачык тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә карар итте:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының « Иске Кәшер авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы проект буенча ачык тыңлаулар билгеләргә.

2. Билгеләргә:

- ачык тыңлауларны оештыручы - Иске Кәшер авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе;

- ачык тыңлаулар үткәрү вакыты - 2022 елның 22 маенда 14 сәгать;

- үткәрелү урыны - Иске Кәшер авылы, Комсомол ур., 4а, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Кәшер авыл җирлеге Советының утырышлар залында (Иске Кәшер авылы, Комсомол урамы, 4а).;

- Комсомол урамы 4а, Сарман муниципаль районының Иске Кәшер авыл җирлеге башкарма комитеты адресы буенча фикер алыша торган мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертелергә мөмкин (эш көннәрендә 8.00 дән 16.00 сәгатькә кадәр (төшке ашка тәнәфес 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр).

4. Иске Кәшер авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектын әзерләү комиссияләре:

- Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының « Иске Кәшер авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы проект буенча гамәлдәге законнар нигезендә һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда ачык тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга;

- ачык тыңлаулар уздыру нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләргә һәм аны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга;

5. Әлеге карарны http/ sarmanovo.tatarstan.ru веб-адрес буенча Сарман муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуныавыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенә йөклим.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Иске Кәшер авыл җирлеге
башлыгы

Р.Н.Дәүләтҗанов

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Иске Кэшер авыл җирлеге
башлыгының 2022 елның 20 апреле
1 нче номерлы
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының « Иске Кэшер авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирләрдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү**

1) 36 статьяның 11 пунктындагы 4 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Җир асты байлыкларыннан файдалануны чикләү һәм тыю

Җир асты байлыкларының аерым участокларыннан файдалану ил оборонасын һәм дәүләт иминлеген тәэмин итү, җир асты байлыкларыннан нәтиҗәле файдалану һәм аларны саклау, әйләнә-тирә мохитне саклау максатларында чикләнергә яисә тыелырга мөмкин.

Торак пунктлар һәм территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналар территорияләрендә җир асты байлыкларыннан файдалану халыкның тормышы һәм сәламәтлеге иминлеге, әйләнә-тирә мохитне саклау куркынычы тудырырга, тау эшкәртмәләренең, бораулау скважиналарының һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле башка корылмаларның сакланышын да кертеп, биналарның һәм корылмаларның сакланышын булдырырга мөмкин булган очракларда чикләнергә яисә тыелырга мөмкин.

Махсус сакланылучы табигать территорияләрендә җир асты байлыкларыннан файдалану аларның территорияләрен махсус саклау режимы нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

2) 27 статьяның 5 пунктындагы 6 пунктча

«6) мондый объектны реконструкцияләгән очракта капиталь төзелеш объектының барлык хокук ияләренең ризалыгы, моңа Россия Федерациясе Җир кодексының 51 статьясындагы 7 өлешенең 6.2 пунктында күрсәтелгән күпфатирлы йортны реконструкцияләү очраклары, блокланган төзелештәге барлык йортларның да бер рәттә төзекләндерелгән йортларның хокукка ия булучыларының ризалыгы кирә»;